РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» сентября 2021 г. г. Альметьевск № 48

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2006 елның 27 гыйнварендәге 26 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 3 өлеше нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2006 елның 27 гыйнварендәге 26 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 04 июлендәге 105, 2015 елның 13 мартындагы 170, 2015 елның 10 декабрендәге 21, 2017 елның 27 июлендәге 88, 2018 елның 11 маендагы 115, 2019 елның 25 мартындагы 148, 2019 елның 25 октябрендәге 176, 2020 елның 12 мартындагы 191, 2021 елның 11 мартындагы 27 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7. Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы,Россия Федерациясе гражданлыгы яки чит ил гражданлыгы туктатылу-чит дәүләт гражданы яки Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә яшәвен раслый торган башка төр документы булганда, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә, чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Шәйхетдинова Ф.А.) йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов